**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы торак пунктында 2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 19 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарысаз-Тәкермән авылы Иске Имән авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Сарысаз-Тәкермән торак пункты зиаратына койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;
-Сарысаз-Тәкермән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
-Сарысаз-Тәкермән торак пунктында Беларусь-МТЗ 82 махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
-СарысазТәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;
-Сарысаз-Тәкермән пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел, Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу;
-Сарысаз-Тәкермән торак пункты өчен генератор сатып алу;
-Янгын ранцы (1 данә), янгын краннары ( 2 данә) сатып алу.

3. Әлеге карарны Иске Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова